СОВЕТ
МАТАКСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МАТАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

Матак авылы

**РЕШЕНИЕ**
2019 елның 12 апреле

**КАРАР**
№ 41/2

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының законга һәм муниципаль норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү мониторингы үткәрү турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 февралендәге 39/2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының законнар һәм муниципаль норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү мониторингын үткәрү турындагы Нигезләмәнең 11 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

икенче абзацта ««Гарант» мәгълүмат системасында» сүзләрен «хокукый мәгълүмат системаларында " сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта ««Гарант» мәгълүмат системасы» сүзләрен «хокукый мәгълүмат системалары" сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «Кодекс» мәгълүмат компаниясенең «Региональ законнар аналитигы» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче абзацны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлегенең Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Матак авыл җирлеге башлыгы В.М.Михайлов